**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛАНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ**
**IV ЧАКЫРЫЛЫШ XI УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 25**

Баланлы авылы 22 октябрь 2021 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы « Баланлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның «23» июлендә 1 номерлы Баланлы авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, шулай ук блокланган торак төзелеше өчен файдаланыла торган җир кишәрлекләренең минималь күләмен 1 000 кв. м күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы башкарма комитетына йөкләргә.

**Баланлы авыл җирлеге** **И.И.Исламова**